РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» март 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 224

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәреше белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 21 октябрендәге 192 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

комиссия составына:

Россия ЭЭМ Кайбыч районы буенча бүлеге башлыгы урынбасары Минһаҗев Гомәр Фаяз улын комиссия әгъзасы итеп (килешү буенча);

Россия ҖҮФХИ ҖҮИ ФКУ ТР буенча Кама Тамагы межмуниципальара филиалы инспекторы Хәбибуллин Булат Рафаэль улын комиссия әгъзасы итеп (килешү буенча) кертергә.

Комиссия составыннан Хуҗин Рушан Галимулла улын, Чернов Дмитрий Василий улын төшерергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Совет Рәисе А.И. Рәхмәтуллин